Текст һәм рәсемнәр: Виллем де Винка

Гайсә Мәсих

БАРЛЫК ЧОРЛАРНЫҢ ИҢ ЗУР ТАРИХЫ




АҢЛАТМА:



ГАЙСӘ = Ходай Улының исеме, ул "Ходай коткара" дигәнне аңлата.

ГӨНАҺ = Ходай ихтыярына каршы килгән һәм ул билгеләгән максатка ирешергә мөмкинлек бирмәгән гамәлләр (4 б.).



ДОГА = Ходай белән эчтән генә яки кычкырып сөйләшү, аны тыңлау. (18, 19,42 б.).

ИЗГЕ РУХ = Гайсә эшен дәвам итүчеләрдә яшәүче Ходай рухы (58 б.).



ИЗГЕ ЯЗМА = грек теленнән тәрҗемә иткәндә, китап дигәнне аңлата. Анда Ходайның кешеләр белән үзара мөнәсәбәтләре турында сөйләнелә.


ИМАН = Ходайның вәгъдәсенә ышанып яшәү (58 б.).



КИЧЕРҮ = Ходай бар кешене дә кичерә, хәтта лаек булмаганнарны да. Ходай безне кылган явызлыгыбыз өчен чын күңелдән үкенгәндә һәм үзгәрергә әзер булганда кичерә. Кичерү Гайсәнең безнең барыбыз өчен дә җәза алуы аркасында мөмкин булды (58 б.).



КОТЫЛУ БӘЙРӘМЕ = Гайсәнең үлеп терелүенә багышланган христиан бәйрәме. Яһүдләрнең Котылу бәйрәме Изге Язма тарихының башка вакыйгасына – яһүдләрнең Мисырдан чыгуына багышлана (38-54 б.).



КЫЯМӘТ КӨНЕ = Гайсә җиргә кире әйләнеп кайткач, бар нәрсәнең яңадан терелүе. Ходайның күкне һәм җирне яңартуы (57 б.).

МӘҢГЕЛЕК ТОРМЫШ = Ходай кушканча, Гайсә турында уйлап яшәү. Мондый тормыш үлемне җиңә һәм беркайчан да бетми (23, 29-30 һәм 59 б.).

МӘСИХ = изге май белән сыланган патша. Мәсих (яһүд телендәге "машиах" сүзеннән) грекча Христос кебек яңгырый (52,55 б.).

ӨЛЕШ АЛУ = Гайсәнең эшен дәвам итүчеләр аның үлемен һәм терелүен шәраб һәм ипи белән искә алалар (41 б.).

ТЕРЕЛҮ = Гайсәнең үлеп терелүе. Килер бер көн, үлгәннәрнең барысы да тереләчәк. Шул чакта Ходай барлык кешеләрне хөкем итәчәк (53-57 б.).

ФАТИХА = Ходайның сүзләрен үтәп яшәүче кешеләргә бирелә торган яхшылыклар (10-11 б.).

ФӘРЕШТӘ = Ходайның күзгә күренми торган хәбәрчесе (5 б.)

ХАЧ = Гайсәнең үз ихтыяры белән үлемне кабул иткән, җәзалау коралыннан мәңгелек Коткару һәм Өмет символына әверелгән хәтер билгесе. (25,48,50 б.).

ХОДАЙ ПАТШАЛЫГЫ = кешеләр Ходайны кайда тыңлый, Ходай Патшалыгы шунда була.

ХОДАЙ УЛЫ = Гайсә – Ходай Улы һәм җиргә кеше булып килгән Ходайның Үзе.

ШАЙТАН = Ходайның һәм кешеләрнең күзгә күренмәс дошманы (Иблис дип тә йөртәләр).

ШӘКЕРТ = Гайсәнең укучысы (18 б.).



КЕМ УЛ ГАЙСӘ МӘСИХ?


Гайсә якынча 2000 еллар элек хәзерге Исраил дәүләте урнашкан урында яшәгән. Без аны Мәсих яки Христос дип атыйбыз. Бу – патша дигән сүз. Ләкин ул гади патша гына түгел. Гайсәне Ходай Улы дип тә, Адәм Улы дип тә атыйлар, бу аның бер үк вакытта Ходай да, кеше дә икәнлеген күрсәтә. Гайсәнең тормыш юлы Изге Язмада бирелгән, бу барлык заманнарның иң бөек тарихы.

ГАЙСӘ ЗАМАНАСЫ

Безнең эра Гайсә туган көннән алып исәпләнә. Ул чакта кешеләр ишәк, дөя һәм атка атланып сәяхәт иткәннәр. Хәзерге Аурупа, Якын Көнчыгыш һәм Төньяк Африканың күпчелек өлеше Рим империясе составына кергән. Кешеләрнең күбесе укый-яза белмәгән, әмма Исраилдәге яһүдләр укымышлы булганнар. Аларны «китап халкы» дип йөрткәннәр.

Ходай кешеләргә Китап, Изге Язма аша мөрәҗәгать итә. Ул бар нәрсәне барлыкка китерүче һәм һәрбер кеше белән дус булырга тели. Гайсә моны безгә ачык күрсәтте!





ИСРАИЛ ГАЙСӘ ЗАМАНЫНДА

Башкаласы: Иерусалим

Өлкәләр: Гәлиләя, Самарея, Яһүдия

Территориясе: якынча 28000 км2


Климаты: Субтропик.

Сәяси хәле: Б.э. к. 63 нче елдан Исраил җире белән римлылар идарә иткән.


Хөкүмәт: Яһүдиядә, Самареяда һәм Эдом җирендә рим хакиме Понтий Пилат идарә итә, аннан югарырак хаким Тиберий була.


Дин: яһүди дине, Иерусалимда яһүдләрнең гыйбадәтханәсе була. Руханилар анда тиешле йолаларны үтәгәннәр, ә канун укытучылары (мәсәлән, фарисейлар) халыкка Изге Язманы өйрәткәннәр.


Телләр: арамей һәм яһүд (яһүдләр теле), грек теле (халыкара аралашу чарасы), латин теле (римлылар теле).




Нигә бөтен кеше елга янына җыелган ул?


Әзерләнегез, Күкләр Патшалыгы инде бик якын!


Яңа тормыш башлагыз!
Ходай хөкеменең балтасы инде агач тамырлары өстендә ята…
Җимеш бирми торган агачны, кисеп, утка ташлыйлар!
Алайса безнең барыбызны да кырып бетерергә кирәк инде: бу дөньяда изгеләр юк!
Әйе! Ходай каршында барысы да гаепле. Ләкин сиңа яңа тормыш бирә ала торган кеше минем арттан килә!
Кылган эшеңә үкен һәм чукыну өчен суга кер!
Бу синең тормышны яңадан башларга теләвеңне күрсәтә.


Дингә өндәүченең исеме – Чумдыручы Яхъя.
Мин беркем дә түгел. Сезгә Ходайны күрсәтер кешенең килүенә генә әзерләнәм. Ул сезне Ходай Рухы һәм уты белән чукындырачак. Сез яңа кешеләр булачаксыз!
Һәм шул чакта...
Сине чумдырыргамы?... Син мине чумдырырга тиеш идең!
Без Ходай ихтыярын үтәргә тиеш.
Шул чакта күктән тавыш ишетелә:
Син – Минем Улым. Мин сине яратам. Син Мин теләгәнчә эшлисең.
Атабыз, Патшалыгың килсен, ихтыярың үтәлсен!

Бу вакыйгалар безнең эра башында була. Израил ул вакыттагы бик зур Рим империясенең бер өлеше генә булган.

Кәпәрнаум
Насара
Кәна
Гәлиләя
Үрдүн
Иерусалим
Яһүдия
ИСРАИЛ

Израил халкы үзен көчсез һәм җәберләнгән итеп хис итә. Алар түземсезлек белән Мәсихне көтә. Мәсих – борынгы яһүд китапларында ук искә алынган коткаручы ул. Мәсих Җир йөзенә Ходай хаклыгын алып килергә тиеш.

Үрдүн елгасы буенда Чумдыручы Яхъя Гайсәгә күрсәтеп:

Карагыз! Менә ул, дөньяның гөнаһларын үз өстенә алачак Ходай корбаны.

Чумдырылганнан соң, Ходай Рухы Гайсәне чүлгә җибәрә.

Гайсә кыргый чүлдә кырык көн һәм кырык төн үткәрә. Ул бу көннәрдә берни дә ашамый. Ашаудан тыелу вакытында һәм догалар укыганда, ул үзе белән булачак хәлләргә әзерләнә.

Шайтанны җиңәр өчен, Гайсә кешеләргә Ходайның аларны яратуын, шайтан хакимлегеннән, җимерелүдән һәм үлемнән азат итәргә теләвен күрсәтергә тиеш.

Әйе, Атабыз, мин син теләгәнне эшләрмен.


Гайсәгә караңгылыкның күзгә күренмәс хөкемдары, дөньядагы үлем һәм җимерү аша хаким итүче – шайтан белән көрәшергә туры киләчәк.



Әмма шайтан Гайсәгә аны максатыннан читкә җибәрә ала торган фикерләр пышылдый.
Юк! Изге Язмада: "Кеше икмәк белән генә түгел, иң элек Ходай сүзе белән яшәячәк", – диелгән.
Ходай улы булсаң, ташларны икмәккә әйләндер!


Ходай Улы булсаң, моны исбатла. Гыйбадәтханә түбәсеннән сикер. Әгәр бу дөрес булса, фәрештәләр сине күтәреп алырлар.
Юк! Изге Язмада: "Ходайга каршы чыкма!" – диелгән.


Кара! Әгәр син миңа баш исәң, мин сиңа Җирдәге бөтен хакимлекне бирермен.
Юк! Изге язмада болай диелгән: "Ходаегызга табыныгыз һәм Аңа гына хезмәт итегез!" Кит моннан, шайтан.


Шуннан соң шайтан Гайсәне күпмедер вакытка калдырып тора. Гайсәгә хезмәт итәргә фәрештәләр киләләр.


Гайсә Гәлиләягә кайта. Ул Исраилнең төньягында урнашкан бу кечкенә генә өлкәдә туып үскән була. Юлда Гайсәгә берничә кеше кушыла. Алар Гайсәнең чыннан да Мәсихме икәнен белергә телиләр...


Гәлиләянең Кәна авылында туй бара...
Бәйрәмдә әнисе һәм берничә дусты белән Гайсә дә катнаша.


Ләкин бәйрәм уртасында…
Коточкыч хәл! Шәраб бетте!
Гайсәдән нишләргә икәнен сора әле.
Бу зур чүлмәкләрне су белән тутырыгыз да, мәҗлес оештыручыга эчеп карарга бирегез.
?
Су? Бу бит шәраб! Иң яхшы шәраб!
Эчеп кара әле! Иң яхшы шәрабны иң ахырга калдырганнар!
Менә сиңа мә! Мондый түйда булганым юк иде әле минем! Су шәрабкә әйләнсен инде! Нинди шәрабкә бит әле!
Моны Насарадан килгән Гайсә эшләде!
Кем соң ул?


Кәпәрнаум – Геннисарет күле буендагы балыкчылар бистәсе. Монда Гайсә кешеләргә Ходай Патшалыгы турында сөйли башлый.



Шунда ук ул үзенең беренче шәкертләрен сайлый.


Петер, ераккарак китеп, ятьмәләреңне шунда ташла әле.


Без төне буе балык тоттык, бернәрсә дә эләкмәде.



Шулай дисең икән инде...



Кит инде! Булмас!



Ягъкуб! Яхъя! Монда килегез! Мондый зур балыкның эләккәне юк иде әле!
Мин куркам! Кит моннан! Мин гөнаһлы гади кеше.
Курыкма, Петер!
Әйдәгез минем белән! Мин сездән кеше аулаучы ясармын!
Минем арттан барыгыз!

Гайсә үзенең шәкертләре белән бөтен Гәлиләя буйлап йөри. Ул якынлашып килүче Ходай Патшалыгы турында сөйли. Гайсә авыруларны савыктыра һәм юләрләнгән кешеләрдән җеннәрне куып чыгара. Халык, сокланып, аның артыннан иярә. Кешеләр аның янына ерак җирләрдән, хәтта Исраил башкаласы Иерусалимнан да киләләр. Алар Гайсәнең һәр сүзен йотлыгып тыңлыйлар.











Башкалардан нинди мөнәсәбәт көтәсез, аларның үзләренә дә шундый мөнәсәбәт күрсәтегез.
Дошманнарыгызны яратыгыз һәм алар өчен дога кылыгыз.
Игелекле эшләрне яшерен генә эшләгез, игътибарны җәлеп итәр өчен түгел.
Хатын-кызга нәфес белән караган кеше инде гөнаһ кылган булып санала.
Күз – тәннең чагылышы. Әгәр күзең нурлы икән, синең дөньяң якты. Ә инде күзең явызлык белән томанланган икән, ул чагында Син караңгыда яшисең.
Берәү дә ике хуҗага хезмәт итә алмый. Я Ходайга хезмәт итәсең, я акчага.
Иртәгесе көн турында кайгыртмагыз. Иң элек Ходай Патшалыгы турында уйлагыз. Калганын Ходай үзе хәл итәр.
Әгәр син мин әйткәннәрне үтисең икән, димәк, йортыңны таш нигезгә төзисең дигән сүз. Әгәр үтәмисәң икән, син йортыңны комда саласың.


Бервакыт Гайсәнең Кәпәрнаумдагы йорты тирәсендә күп халык җыела…
Без моннан берничек тә үтә алмыйбыз.
Алайса ятакны күтәреп, түбә аша узыгыз!
Әй, нәрсә бар анда?
Тимә аларга! Алар моңа чын күңелдән ышаналар!
Синең гөнаһларың кичерелде!
Син аның нәрсә әйткәнен ишетәсеңме?
Ул Ходайны мыскыл итә!
Гөнаһларны Ходай гына кичерә ала!
Нәрсә дип әйтү җиңелрәк: «гөнаһларың кичерелде» дипме, әллә «тор да йөреп кит» дипме?
Тор, урын-җиреңне ал да өеңә кайт. Синең гөнаһларың кичерелде!



Ләкин Гайсәнең эшләгән эшләре һәм сөйләгән сүзләре бөтен кешегә дә ошамый. Исраилнең дини остазлары һәм җитәкчеләре аның кануннарны үтәү-үтәмәвен игътибар белән күзәтәләр. Исраилдә, мәсәлән, шимбә эшләү тыела.














Гайсә көймәдә шәкертләре белән Геннисарет күленең икенче ягына китә.
Остазыбыз! Булыш! Без батабыз!
Нигә шулай куркасыз? Ник ышанмыйсыз?


Тыныч лан! Тукта!
Алар тын урынга килеп туктыйлар. Шул чак тауларда…
Р-Р-А-А-А!


Тауларда җен кагылган кеше яши.
Х-Х-Х!
Килә!
Я, я, Гайсә!
Мин сиңа нәрсәгә кирәк булдым әле, Ходай улы?
Явыз рух, бу адәмнән чыгып кит!
Исемең ничек?
Легион. Монда без бер армия!
Безне әнә теге дуңгызлар янына җибәр, шулар эченә керик әле.
Барыгыз!


?
Мин сау-сәламәт!
Кит! Кит моннан!
Миңа сезнең белән барсам буламы?
Юк, син монда кал. Ходайның сиңа нинди мәрхәмәт күрсәтүен бөтен кешегә дә сөйләп бир!

Әйтәм бит: Ходай улы бернәрсәне дә үз теләге белән эшләми. Ул Атасы кушканны гына эшли. Мин үзем теләгәнне эшләмим, ул теләгәнне эшлим: мине ул җибәрде бит.

Ходайга гыйбадәт кылу өчен, Гайсә еш кына ялгыз кала иде.

Төнге гыйбадәттән соң, Гайсә үзенә унике шәкерт сайлап ала. Ул аларга явыз рухларны куып чыгару һәм кешеләрне төрле чирләрләп савыктыру кодрәте бирә. Гайсә Исраилнең барлык шәһәрләренә икешәр шәкертен җибәрә.

Болар – абыйлы-энеле Петер белән Әндри…

Кардәшләр Ягъкуб һәм Яхъя…

Филип белән Бартулумай…











Унике шәкерт Гайсә янына әйләнеп кайта. Гайсә алар белән ялгыз гына калырга тели. Ләкин халык аларга ирек бирми.




Гайсә вәгазь сөйләгәндә һәм дәвалаган арада, караңгы төшә…
Филип, бу кешеләр ач! Аларга ашарга бирергә кирәк!
Аларга ризык сатып алыргамы? Моның өчен ике йөз алтын тәңкә дә җитмәс!
Менә бер малайның биш ипие белән ике балыгы бар. Башка бернәрсә дә юк.
Кешеләр төркем-төркем булып, иллешәрләп утырсыннар.
Гайсә Ходайга рәхмәт әйтә…
...һәм аларга ипи белән балык өләшә башлый.


Меңләгән кеше Гайсә биргән ризык белән туена.
Аны патша итәргә кирәк!
Ул, чыннан да, без көткән Мәсих.
Карагыз! Тагын унике кәрзин калды бит әле!
Бу кешеләрне өйләренә кайтарып җибәрергә вакыт. Мин монда гыйбадәт кылырга калам. Ә сез күлнең теге ягына йөзеп чыгыгыз.


Шул ук төнне…
Курыкмагыз! Бу Мин!
Аһ! Өрәк!
Ходаем, бу син булсаң, Миңа су өстеннән атлап килергә куш!
Бар, Петер!
Коткар мине!
Син нигә шикләнеп калдың, Петер?

Кайберәүләр Гайсәне патша итеп игълан итәргә тели. Алар, ул җитәкчелек иткәндә, Рим илбасарлары куылыр дип өметләнә. Шул ук вакытта Гайсәнең дошманнары һәм көндәшләре арта бара.















Гайсә, Гәлиләяне калдырып, Исраилнең башка төбәкләрендә вәгазьләр сөйләвен дәвам итә.
Гәлиләя
Иерусалим
Исраил
Иерусалимга барганда.
Халык мине кем дип уйлый?
Күпләр сине пәйгамбәр дип саный.
Юлда...
Ә сез?
Ә сез мине кем дип саныйсыз?
Син – Тере зат булган Ходайның Улы Мәсих.
Бу турыда беркемгә дә әйтмәгез. Мәсих Иерусалимга барып, анда газап чигәргә һәм үләргә тиеш. Ләкин өченче көн дигәндә, ул терелер.


Үлем җәзасы ул вакытта гадәти эш булган. Рим йоласы буенча хөкем ителгәннәрне тәрегә кадаклыйлар. Алар газапланып үләләр.


Минем шәкертем булырга теләгән кеше, үз-үзен онытып, хачын күтәрсен дә минем арттан барсын.


Кем үз тормышына ябышып яши, шул аны югалтыр. Ә минем хакка үз гомерен биргән кеше аңа яңадан ия булыр.


Ходай берәү генә. Аннан башка Ходайлар юк.


Ходайны бөтен барлыгың белән ярат. Башкаларны үзеңне яраткан кебек ярат.


Ул вакытта Исраилдә махау чире белән авыручылар өчен аерым авыллар булган. Бу бик куркыныч авыру. Авырулар сәламәт кешеләргә кагылырга да тиеш булмаган.
Махау чире йоктырган кешеләр берәр җиргә барсалар, каты кычкырып, алдан ук үзләре турында кисәтергә тиеш булганнар.
Без – махау авырулы!
Без – махау авырулы!
Гайсә! Остазыбыз! Кызган безне!


Барыгыз, руханига күренегез.
Йола буенча без, терелгәч кенә, руханига күренә алабыз....
Без кайчан тереләчәкбез?
?
!
Махау чире башка юк!
Без сәламәт!
Сау-сәламәт!
Ходаем! Рәхмәт Сиңа!
Тугызы да савыктымы? Башкалар кайда соң? Нигә алар рәхмәт әйтергә килмәделәр?
Тор! Ходайга ышануың сине савыктырып кына түгел, коткарып та калды.

Иерусалим башлыклары, Гайсәне күзәтеп торыр өчен, үз кешеләрен җибәрәләр. Алар аны кануннарны һәм гореф-гадәтләрне бозучы дип саныйлар.

Фахишәләр, салым җыючылар, римлыларның хезмәтчеләре... Башкалар алар белән хәтта исәнләшмиләр дә. Гайсә исә алар белән сөйләшүне түбәнлеккә санамый.

Мәсих юлдан язганнарны коткарырга килгән.

Шимбә көнне эшләү тыелса да, Гайсә авыруларны дәвалый.


Син терелдең!


Ул балаларга аеруча игътибар бирә…

Балалар минем яныма килсеннәр. Ходай Патшалыгы бала кебек самими кешеләр өчен яралган.

Гайсәне Иерусалим янындагы Бәйт-Әния дигән бер авылга чакыралар. Анда Элгазар исемле бер кеше авырып киткән була. Элгазар һәм аның сеңелләре Марта белән Мәрьям Гайсәнең якын дуслары була. Әмма Гайсә, Бәйт-Әниягә килеп җиткәндә, Элгазарның үлүен һәм дүрт көн элек җирләнүен ишетә.

















Кара, ул аны чыннан да яраткан бит!
Ул Элгазарны үлмәслек итеп эшли алмадымы икән?
Борынгы Исраилдә үлгәннәрне, күмү тукымаларына төреп, кыяда уелган төрбәгә салганнар.
Ташны төрбәдән алыгыз! Ачыгыз аны!
Син истән курыкмыйсыңмы? Ул анда дүрт көн бит инде…
Сез хәзер Ходайның нинди могҗизалар кыла алуына инанырсыз.
Атам, мондагы кешеләр мине Син җибәргәнне белсеннәр!
Чык, Элгазар!
Күмү тукымаларын чишегез. Торсын.










Әмма үлем җәзасын үтәү хокукы Римлыларга бирелгән. Иерусалим руханилары Гайсәне Римлыларга бирер өчен сылтау эзлиләр.



Ул арада Иерусалим янындагы Бәйт-Әниядә...
Мәрьям!
Исле май! Ул бит шулхәтле кыйбат!
Без ул акчаны ярлыларга бирә алыр идек!
Тимә аңа, Яһүдә! Ул абу майны мине күмү өчен саклый.


Котылу бәйрәме якынлаша.
Хаҗилар Иерусалимга агыла.



Үзенең кулга алынуын
һәм җәзаланырга
мөмкин булуын белсә
дә, Гайсә дә
Иерусалимга бара.


Кешеләр аны сокланып каршы алалар....
Һошанна!
Һошанна!
Ходай исеменнән килгән кешегә мактаулар яусын!
Исраил Патшасы!
Иерусалим, син тынычлык өчен нәрсә киряклеген белсәң икән. Ләкин син белергә теләмисең.
Моңа юл куярга ярамый!
Алар барысы да аның дәвамчылары булачак.

Иерусалим Гыйбадәтханәсе – бәйрәм үзәге.




Яһүдиләр Котылу бәйрәме вакытында бәрәннәрне суялар.



Бәрән каны – гөнаһлардан котылу өчен кешеләрнең Ходайга биргән корбаны.



Корбан бәрәне кешеләрне гөнаһларыннан чын мәгънәсендә азат итә аламыни?




Гыйбадәтханә мәйданында халык бик тырышып сату итә һәм акчаларын алмаштыра.




Көтмәгәндә, анда Гайсә пәйда була…




Гыйбадәтханә гыйбадәт кылу урыны булырга тиеш. Ә сез аны юлбасарлар мәгарәсенә әйләндергәнсез.
Ул хәтәр кеше! Карагыз, кешеләр аның һәр сүзен тыңлыйлар.
Безгә, һичшиксез, аннан котылырга кирәк!






Без аны берәр хәйлә белән эләктереп алып үтерергә тиеш.
Ләкин бәйрәм вакытында түгел. Котылу бәйрәме вакытында безгә шау-шу кирәкми.


Аның өчен сез миңа күпме бирәсез?
Бу – Яһүдә, аның бер шәкерте!



Мин сезгә Гайсәне тотып бирермен!


Ал! Менә утыз көмеш тәңкә.



Руханилар аңа комачауларга тырышсалар да, Гайсә Иерусалим гыйбадәтханәсендә Котылу бәйрәменә кадәр вәгазь сөйли. Гайсәнең шәкертләре Котылу бәйрәменә бәрәннән кичке аш әзерлиләр.









Кичен Гайсә һәм аның унике шәкерте Котылу бәйрәменә җыелалар.






Газапларым башланганчы, бу Котылу бәйрәмен сезнең белән үткәрәсем килгән иде.
Хакимнәр халык белән идарә итә. Сездә киресенчә булырга тиеш.
Сезнең җитәкчегез булган кеше үзе сезгә хезмәт итәргә тиеш.
Мин сезнең арагызда хезмәтче кебек!


Син нәрсә, кол кебек минем аягымны юмакчы буласыңмы әллә? Юк! Булмас!
Риза булмасаң, димәк, син минем укучым түгел.
Алайса, кулларымны да, башымны да ю...
Син чиста. Аякларыңны юу да җитәр.
Сез мине үзегезнең остазыгыз һәм Ходаегыз дип атыйсыз. Дөрес. Ләкин мин хезмәтче кебек сезнең аякларыгызны юдым. Сез дә бер-берегезгә хезмәт итегез.
Арагыздан берегез миңа хыянәт итәчәк.
Беркайчан да!
Мин түгелме?
Яһүдә, уйлаганыңны тизрәк тормышка ашыр!


Моны эшләгәндә, һәрвакыт мине истә тотыгыз…
Бу ипине алыгыз. Ул минем тәнем.
Менә бу чынаякны алыгыз. Анда минем сезнең өчен коелган каным. Ул Ходай һәм кешеләр арасындагы яңа бердәмлек билгесе.
Мин сезгә яңа васыять калдырам: мин сезне ничек яратсам, сез дә бер-берегезне шулай яратыгыз.
Бер-берегезне яратсагыз, барысы да сезнең минем укучыларым икәнне аңларлар.
Ходаем, мин синең арттан теләсә кая барырга әзер. Мин синең өчен җанымны да бирермен.
Юк, Петер, таң әтәчләре кычкырганчы ук, син миннән өч тапкыр ваз кичәрсең.


Кич җиткәч, Гайсә унбер шәкерте белән шәһәрдән чыгып китә. Яһүдә алар белән булмый…
Мин китәм, ә Атам сезгә изге рухны җибәрер. Ул сезне юатыр һәм мәңгегә сезнең белән калыр.


Мин барасы юлны сез яхшы беләсез.


Мин – юл да, хакыйкать тә, тормыш та. Атабыз янына илтә торган юл бары минем аша гына.


Монда калып торыгыз. Мин гыйбадәт кылып киләм.


Атам, мөмкин булса, бу газаплар мине читләтеп үтсен иде.


Мин теләгәнчә түгел, ә син әйткәнчә!


Йоклыйсызмы? Торыгыз! Әнә минем хыянәтчем килә!
Мин кемне үпсәм, шул Гайсә булыр, Аны кулга алыгыз.
Сәлам, Остазым!
Яһүдә, шушы үбүең белән син Мәсихкә хыянәт итәсеңмени?
Ходаем, бәлки безгә сине якларга кирәктер?
Кирәк ми!
Гайсә гаскәриләргә үзен кулга алырга мөмкинлек бирә. Укучылар таралышалар.


Гайсәне Иерусалимдагы руханиларның башлыгы янына алып киләләр. Петер белән Яхъя да шыпырт кына Гайсәгә иярәләр.



Петер ишегалдына керә.


Әй! Син дә аның белән идең бит?
Юк, белмим мин аны!


Син – шуларның берсе!
Юк инде!


Әйе инде! Син Гәлиләядән! Синең хәтта сөйләшүең дә шуларныкы шикелле!
Мин сезнең нәрсә турында сөйләгәнегезне дә аңламыйм.



Ки-кри-кук!
Гайсә Петергә күз ташлый.
Я, әйт әле: кем сукты сиңа?
Иртән Гайсәне Иерусалим руханилары җыелышына алып киләләр.
Әйт әле: "Син Ходай улымы?"
Сез үзегез шулай дисез бит.
Көферлек бу! Үлем аңа! Римлылар аны җәзалап үтерсеннәр!


Гайсәне Рим идарәчесе Понтий Пилат янына алып баралар. Халыкны да Гайсәгә каршы котырталар. Аңа мәгънәсез гаепләр тагалар.
Бу гаепләүләргә Син ни диярсең? Нигә дәшмисең?
Мин аның бер гаебен дә күрмим. Хәзер Котылу бәйрәме. Кемне азат итим: Барабнымы, Гайсәнеме?
Ә дөреслек нәрсә соң ул?
Син нәрсә эшләдең?
Мин дөреслек турында шаһитлек бирү өчен килдем.


Барабны!
Барабны!


Гайсәне нишләтим?
Хачка кадакла Аны!
Ул Үзен патша дип саный!
Әгәр син аны азат итсәң, димәк, син Рим императорының дошманы!


Чык.
Барабны азат итәләр. Ул сәяси үтерү өчен хөкем ителгән була.


...37, 38, 39!


Аның үлемендә мин гаепле түгел.


Яшәсен яһүдләр патшасы.


Менә сезнең каршыгызда ул кеше!
Хачка Кадакла Аны!
Хачка Кадакла Аны!
Хачка Кадакла!


Пилат үлем карарына кул куя: хачка кадакларга. Гадәттә, хөкем ителгән кеше үз хачы өчен агачны җәзалау урынына үзе алып килә.


Җәзалау урыны шәһәр читендә була. Ул Гөлгетә (баш сөяге) дип атала.



Гайсәне хачка кадаклап куялар.




Яһүдә үзенең хыянәте өчен бик үкенә.
Мин моны теләмәгән идем…
Мин бер гаепсез кешене харап иттем!!!
Шуннан ни? Анысы инде синең хәсрәтең.
Гайсәне ике җинаятьче арасына кадаклап куялар.
Атам, кичер аларны! Алар нәрсә эшләгәннәрен үзләре дә белмиләр.


Пилатның боерыгы буенча хачка өч телдә "Гайсә – яһүдләр Патшасы" дигән язу беркеттеләр.
IESVS NAZARENVS REX IVDAEORVM
ΙΗΣΟΥΣ Ο ΝΑΖΩΡΑΙΟΣ ΟΒΑΣΙΛΕΥΣ ΤΩΝ ΙΟΥΔΑΙΩΝ
Гайсә авыруны баса торган эчемлектән баш тарта.
Солдатлар Гайсәнең киемнәрен бүлешә башлыйлар.
Я, башкаларны коткарырга теләгән идең, үзеңне коткара аласыңмы соң?
Ходай Улы булсаң, хачтан төш!
Әйдә, үзеңне дә, безне дә коткар!
Ходайдан курык. Һәркем үзенә тиешлесен ала. Ә ул бернинди дә начарлык эшләмәде.
Патшалыгыңа баргач, мине исеңә ал!
Ышан миңа, син бүген үк минем белән оҗмахта булырсың.


Төш вакытында көтмәгәндә караңгылык төшә. Нәкъ өч сәгатькә кояш юкка чыга.
Хач янында Гайсәнең анасы Мәрьям һәм аның шәкерте Яхъя басып тора.
Сез хәзер ана белән ул.
Я Ходам, я Ходам! Нигә ташлап киттең мине?
Минем эчәсем килә!
Атам! Җанымны синең кулларыңа тапшырам.
Бетте...


Гайсә көндезге өчләр тирәсендә үлә. Солдатлар хачта асылынып торган гәүдәгә сөңге белән чәнчиләр. Ярадан кан һәм сүл ага.


Изге язмаларда моның турында: "Аны чалырга алып барган сарык шикелле алып бардылар", – дип әйтелә.



"Аны безнең гөнаһларыбыз өчен җәфалаганнар һәм газаплаганнар". Ә хәзер инде ул вафат.


Ул шул безгә килергә тиешле Мәсих булып чыктымы инде?


Әйдәгез, сорап карыйк, бәлки, безгә аны күмәргә рөхсәт итәрләр.


Ариматайлы Йосыф белән Никәдим, Гайсәнең тәненә хуш исле майлар сөртеп, кәфенлеккә төреп, аны төрбәгә салалар.Төрбә – кыяда уелып ясалган мәгарә. Аңа керү юлын зур таш белән каплыйлар.


Икенче көнне кайгыга төшкән берничә хатын-кыз төрбә янына киләләр...
Таш читкә этеп куелган!
Нигә сез мәетләр арасында тере зат эзлисез? Ул терелде. Моның турында аның укучыларына сөйләгез!
Бу хакта ишеткәч, Петер белән Яхъя төрбә янына йөгереп киләләр.
Ни булды?
Монда беркем дә юк!


Төрбә янындагы бакчада…
Ник елыйсың? Кемне эзлисең син?
Аның гәүдәсен син алып киттеңме?
Мәрьям!
Остазым!
Кагылма миңа, Мәрьям! Шәкертләремә минем Атам-Ходам янына китүемне сөйлә. Ул сезнең дә Ходаегыз!


Шул ук көнне Гайсәнең Иерусалимннан Эммаус шәһәренә барган ике шәкерте юлда очраган бер кеше белән аның үлеме турында сөйләшәләр. Алар бу хәлгә бик борчылуларын әйтәләр.
Әллә сез пәйгамбәрләргә ышанмыйсызмы? Мәсих данга ирешкәнче, газап чигәргә тиеш иде бит! Боларның барысы да безнең Язмаларда алдан ук әйтелгән иде инде!


Төшке аш вакытында Кунак кинәт юкка чыга...
Бу бит Гайсә иде!


Алар, ашыгып, башка шәкертләр янына кайталар.
Мәрьям белән Петер да күргәннәр!
Без Аны күрдек!


Кинәт...
Иминлек сезгә!


Сез моның Мин булуына ышанмыйсызмы? Кулларыма, аякларыма карагыз әле!



И Ходам!

Кырык көн рәттән Гайсә үзенең шәкертләре янына килә. Аны хәтта берьюлы биш йөз кеше күрә! Бервакыт берничә шәкерте Гәлиләя күлендә балык тотканда…














Петер, син мине яратасыңмы?
Гайсә бу сорауны Петергә өч тапкыр бирә....
Әйе, Остазым, мин сине яратканны үзең дә беләсең.
Алайса Минем бәрәннәремне күздән ычкындырма!
Минем арттан бар!
Мин күктә дә, җирдә дә бар нәрсә өстеннән хакимлек итә алам. Дөнья гизегез, вәгазьләр сөйләгез. Барлык кешеләр дә минем шәкертләрем булсыннар. Аларны Ата, Угыл һәм Изге Рух исеме белән суга чумдырыгыз. Аларны мин әйткәнчә эшләргә өйрәтегез.
Исегездә тотыгыз: мин дөньяның соңгы көненә кадәр сезнең белән булырмын.
Шушы сүзләрне әйтеп, Гайсә безнең җиребезне ташлап китте. Ул күккә ашты. Ләкин ул кешеләрне хөкем итәр өчен кире кайтыр...


Гайсәнең шәкертләре, гыйбадәт кылырга җыелалар һәм Изге рухны көтәләр. Рух алар янына килә! Алар яңа кешеләргә әвереләләр! Хәзер алар, курыкмыйча, Гайсә хакында вәгазь сөйлиләр.








Һәр якшәмбе көнне Гайсәнең эшен дәвам итүчеләр, гыйбадәт кылу һәм Изге Язманы уку өчен, бергә җыелалар. Гайсәнең соңгы көнен искә алып, шәкертләре үзара икмәк бүлеп ашыйлар һәм бергәләп шәраб эчәләр. Ходай аларны бер-берсен яратырга һәм бу яратуны башкалар белән уртаклашырга чакыра. Бу – аларның Ходайны ярату билгесе.


Гайсә безнең өчен Ходайга юл ачты!
Гайсә безне ярата! Син дә Аңа рәхмәтле бул, мактау сүзләре яудыр!
Ходай кешеләрне шулкадәр ярата, алар хакына хәтта үзенең бердәнбер Улын да үлемгә дучар итә. Аңа ышанган кеше алдында мәңгелек тормыш ачыла.
WILLEM DE VINK

ИЗГЕ ЯЗМА

Гайсә тарихы Изге Язмада бирелгән. Аның белән бер генә китап та тиңләшә алмый. Изге Язма 66 китаптан тора. Алар 1500 елдан артык языла. Изге Язманың соңгы китаплары якынча 1900 ел элек язылган. Изге Язмада Ходайның кешеләр тормышында нинди урын тотуы турында күп хикәяләр бар. Гайсә тарихы – Ходайның нинди булуы турындагы иң камил хикәя.

ГАЙСӘ ТАРИХЫ



Изге Язмадагы 4 китап Гайсәнең җирдәге тормышы турында. Бу китаплар авторларның исемнәре белән аталган. Бу авторлар барысы да Гайсәнең замандашлары була.

1. **Маттай** – Гайсәнең шәкерте. Ул салым җыючы була. Ул Гайсәнең Исраил халкы (яһүдләр) өчен эшләгән эшләренә аерым игътибар бирә.

2. **Марк**. Гайсә үз хезмәтен башкарганда, Марк әле малай гына була. Ул Гайсәнең могҗизалары турында күп яза.

3. **Лүк**. Әлеге автор табиб була. Ул Гайсә белән шәхсән таныш булмый. Лүк Гайсәнең кешеләр белән ничек аралашуы турында сөйли.

4. **Яхъя**. Гайсә эшен дәвам итүчеләрнең берсе була. Ул Гайсәнең кем булуы турында сөйли. Гайсә – кешеләрне гөнаһларыннан коткарыр өчен адәм баласына әйләнгән Ходай.


ГАЙСӘНЕҢ ТУУЫ

Гайсә туганда, аның әнисе Мәрьям әле кияүдә булмаган.
Ул гыйффәтле кыз булса да, Гайсәне тапкан. Бу могҗиза турында, ул туганчы ук, изге китапларда язылган була. Гайсә каһарман булып та, ниндидер үзенчәлекле кеше булып та тумаган. Ул терлек абзарында туган, чөнки башка урын табылмаган.

ГАЙСӘНЕҢ МОГҖИЗАЛАРЫ

Гайсә бик күп могҗизалар эшләгән. Изге Язмада 40тан артык терелү турында сөйләнелә. Гайсә үзенең могҗизалары белән Ходайның кодрәтен һәм мәхәббәтен күрсәткән. Шулай ук Ходайның кешеләргә ярдәм итәргә һәм аларны бәхетле итәргә теләве турында җиткергән.





ГАЙСӘНЕҢ ҮЛЕМЕ ҺӘМ ТЕРЕЛҮЕ



Ни өчен Гайсә үлгән? Изге Язма моңа җавап бирә.

Кайвакыт бөтен кешеләр дә явызлык эшлиләр. Ходайга ярамаган һәм аның ачуын китергән бу гамәлләр гөнаһ дип атала. Гөнаһлар кешеләргә Ходай белән дус булырга комачаулый.
Нәкъ менә шуңа күрә Гайсә килә дә инде, ул безнең гөнаһларыбыз җәзасын үз өстенә ала. Бу җәза үлем була. Гайсә безнең өчен үлгәнгә күрә, без тагын Ходай белән дус була алабыз. Әгәр без явызлык эшлибез икән, без моның өчен үкенергә тиеш.
Гайсә үледән терелә. Ходай аны терелтә һәм Үзенең үлемнән көчлерәк икәнен исбатлый.
Хәзер Гайсә Ходай белән яши. Ул исән, шуңа күрә безгә һәрвакыт дустыбыз буларак ярдәмгә килә ала. Ул безгә Ходайны шатландырып яшәргә ярдәм итәргә тели.

ДОГА

Әгәр син кылган ялгыш гамәлләрең өчен үкенәсең һәм Ходайның дусты булырга телисең икән, болай итеп дога кыла аласың:
"Ходаем, син мине яратасың.
Син бердәнбер улың Гайсәне биргәнсең,
Ул мин эшләгән барлык явызлык өчен хачта үлсен дип.
Үтенеп сорыйм, кылган явызлыгым өчен кичер мине, мин моңа бик үкенәм.
Гайсәнең минем янга килүе өчен рәхмәт сиңа.
Мин һәрвакыт синеке булырга телим,
Син миңа үзең теләгәнчә яшәргә булышырсыңмы?
Син һәрвакыт минем белән янәшә булырсыңмы?
Догама җавап биргәнең өчен рәхмәт
Син һәрвакыт вәгъдәңне үтисең!"

ГАЙСӘ ҺӘМ СИН

Гайсәнең тарихы тәмамланмады. Гайсә элек яшәүчеләрнең дә, бүгенгеләрнең дә дусты булып тора. Дөнья үзгәрде. Без инде ишәк, дөя яки атларда йөрмибез, ә машина һәм очкычларда сәяхәт итәбез. Ләкин Гайсә үзгәрмәде. Исраил җирендә йөргән вакыттагы кебек үк, ул бүген дә безгә якын булырга мөмкин.

Ул күренмәскә дә мөмкин, ләкин ул бар. Ул бүген синең дустың булырга тели. Син аны тыңлый һәм ярата аласың.

Син Гайсә турында һәм аның белән булу турында күбрәк белергә телисеңме? Ул чагында түбәндәгеләрне эшли аласың:

1. **Изге Язманы укый башла**
(мәсәлән, Лүк язган хикәядән башла)

2. **Гыйбадәт кыла башла**
(ягъни Ходай белән сөйләш һәм аны тыңла)

3. **Башка кешеләргә Гайсә һәм Изге Язма турында сөйлә**



Текст һәм иллюстрацияләр авторы: Виллем де Винк.
Авторлык хокукы © 1993 Stichting Wereldtaal, Роттердам, Нидерланд.
Нидерланд телендә «Jezus Messias» исеме астында басылып чыккан.
Татар телендәге басма (Татарстан) © 2026
Санлы форматтагы авторлык хокукы Creative Commons BY-SA лицензиясе шартларына нигезләнә.
Тәрҗемә итү, кабат бастыру һәм яраклаштыру хокуклары барлык илләр өчен дә сакланган.
электрон почта: jmpbk.app@gmail.com
https://www.jesusmessiahcomicmedia.com/russia

Бу Гайсә Мәсихнең чын тарихы. Ул хәзерге Исраил дәүләте урнашкан җирдә якынча 2000 ел элек яшәгән. Аның белән очрашкан һәр кеше гаҗәпкә кала торган булган. Ул эшләгәнне беркем дә беркайчан да эшли алмаган. Ул сөйләгән сүзләрне берәүнең дә сөйләгәне булмаган. Гайсә булган җирдә могҗизалар барлыкка килә торган булган. Ул үзен тыңлаган һәркемгә шатлык һәм бәхет бүләк иткән. Кинәт боларның барысы да юкка чыга. Дошманнары Гайсәне җәзалап үтерәләр. Ләкин бу әле соңгы чик түгел. Моның ничек булганын укып чыгыгыз һәм Гайсә Мәсихнең тарихы дәвам итүен белегез!



Language: Tatar (Tatarstan)
Тел: Татар (Татарстан)